**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

18.10.2024 № 1248

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында

«Гражданнар оборонасы турында» 1998 елның 12 февралендәге 28-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә гражданнар оборонасы турында Нигезләмәне раслау хакында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2007 елның 26 ноябрендәге 804 номерлы Карары, «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасы турында» 2020 елның 20 февралендәге 10-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, «Гражданнар оборонасы турында»Татарстан Республикасы Президентының 2008 елның 22 ноябрендәге ПУ-598 номерлы Указы нигезендә Татарстан Республикасында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару", Россия гадәттән тыш хәлләр министрлыгының «муниципаль берәмлекләрдә һәм оешмаларда гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2008 елның 14 ноябрендәге 687 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турындагы нигезләмәне раслау турында» 15.10.2024 ел, № 1229 карары белән, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында гражданнар оборонасы белән идарә итүне оештыру өчен, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Гражданнар оборонасы өлкәсендә гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бурычларны хәл итүгә вәкаләтле орган төзергә, ул алга таба Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Гражданнар оборонасы штабы дип атала..

2. Түбәндәгеләрне расларга:

2.1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында гражданнар оборонасын оештыру схемасы (1нче кушымта);

2.2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Гражданнар оборонасы штабы турында нигезләмә (2нче кушымта);

2.3. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Гражданнар оборонасы штабы структурасы (3нче кушымта);

2.4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы гражданнар оборонасы штабы башлыгының функциональ бурычлары (4 нче кушымта).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе җаваплылыгында калдырырга.

Җитәкче Ә.К. Габдуллин